| ГЛАВА МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

9 ноябрь, 2023 ел Мөрәле ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2023 елның 20 ноябренә 14 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Яшьләр ур, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын билгеләргә***.
2. 2023 елның 21 ноябренә 14 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 45нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.
3. 2023 елның 22 ноябренә 11 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Гагарин ур., 14а нче йорт адресы буенча урнашкан “Ак каен” кибете янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә
4. 2023 елның 24 ноябренә 11 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Үзәк ур., 70А йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***дүртенче этабын*** билгеләргә.
5. 2023 елның 27 ноябренә 10 сәг 00 минутка Мөрәле ав., Карла Маркса ур., 69 нчы йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле

авыл җирлегенең Мөрәле  торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләре буенча гражданнар җыенының  ***бишенче этабын***  билгеләргә

6. 2023 елның  28 ноябренә 14 сәг 00 минутка   Мөрәле ав., Карла Маркса ур.,  34 нчы йорт янында  Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле  торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләре буенча гражданнар җыенының  ***алтынчы этабын***  билгеләргә
7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

- торак пункт территориясендәге рөхсәтсез чүплекләрне   чистарту;
- материаллар сатып алып,урамны яктыртучы утларны ремонтлау;
- торак пункт территориясен карап тоту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, янгын гидрантларын урнаштыру;
- материаллар сатып алып су башнясын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү (насос сатып алу, автоматика һ. б.)
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль  юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып ,юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.»

« РИЗА»                                                «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм  Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://muralin-kaybici.tatarstan.ru./ урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Мөрәле  авыл җирлеге  Башлыгы                                          Р.Р.Зиннатуллин